ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**07.09.2026** **Чистай ш.** **№ 417**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 25 октябрендәге 681 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны «Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм башка категориядәге затларга ярдәм чараларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 елның 10 июлендәге 862 номерлы карарының 10 нчы өлешенә туры китерү, шулай ук күрсәтелгән карар белән җирле үзидарә органнарына бирелгән тәкъдимнәрне үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 25 октябрендәге 681 номерлы карарына (2022 елның 08 декабрендәге 775 номерлы, 2023 елның 07 февралендәге 55 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа 1.9 һәм 1.10 пунктчалар өстәргә:

«1.9. мәдәният, физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы муниципаль оешмаларда, шулай ук җирле үзидарә органнары оештырган күргәзмәләрдә, мәгърифәтчелек, физкультура һәм спорт чараларында булганда ташламалар (бушлай керү) бирергә;

1.10. мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гаиләнең яшәү урынына иң якын муниципаль белем бирү оешмаларына, шул исәптән озайтылган көн төркемнәренә беренче чиратта кабул итүне башкарырга (шул исәптән бер белем бирү оешмасыннан икенчесенә күчергәндә)».

1.2. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Әлеге карарның 1 һәм 3 пунктларында каралган ярдәм чаралары Чистай муниципаль районы территориясендә яшәүче түбәндәге категория затларга күрсәтелә:
а) махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) (бурычларны үтәүгә ярдәм итүче (ярдәм иткән) затларга;
б) Россия Федерациясе дәүләт чигендә һәм махсус хәрби операция (алга таба - кораллы коткы) уздырыла торган районнарга якын Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә кораллы коткы барышында Россия Федерациясе территориясенә кораллы бәреп керүне (алга таба - кораллы бәреп керүне) кире кагу бурычларын үтәүче (башкаручы) затларга;
в) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлары нигезендә, Донецк Халык Республикасы Кораллы Көчләре, Луганск Халык Республикасы халык милициясе, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы хәрби формированиеләре һәм органнары составында 2014 елның 11 маеннан башлап хәрби хәрәкәтләрдә (алга таба - хәрби хәрәкәтләр) катнашкан затларга;
г) әлеге пунктның «а»-«в» пунктчаларында аталган затларның, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашуга (бурычларны үтәүгә), кораллы бәреп керүне кире кагу бурычларын үтәүгә, кораллы коткы барышында, хәрби хәрәкәтләр барышында һәлак булганнарның (вафат булганнарның), хәбәрсез югалган яисә махсус хәрби операциядә катнашуга, күрсәтелгән бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә билгеләнгән тәртиптә хәбәрсез югалган дип танылган, шулай ук вафат булган затларның гаилә әгъзаларына хәрби хезмәттән (хезмәттән, эштән) азат ителгәннән яисә ирекле формированиеләрдән чыгарылганнан соң, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законда каралган, әгәр андый затларның үлеме махсус хәрби операциядә катнашу, күрсәтелгән бурычларны үтәү белән бәйле рәвештә алган гариплек (яралану, җәрәхәтләнү, контузия) яки авыру нәтиҗәсендә килеп чыккан булса (алга таба - гаилә әгъзалары)».
1.3. Карарга түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:
«2.1. Әлеге карарны гамәлгә ашыру максатларында гаилә әгъзалары булып танылалар:
а) ире (хатыны);
б) 18 яшькә җитмәгән, шул исәптән әлеге карарның 2 пунктындагы «а»-«в» пунктчаларында аталган затлар һәлак булганнан (вафат булганнан) соң туган һәм аларга карата ата булуы Россия Федерациясе Гаилә кодексының 48 нче маддәсендәге 2 нче пункты нигезендә билгеләнгән балалар;
в) 18 яшькә җиткәнче инвалид булган 18 яшьтән өлкәнрәк балалар;
г) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда көндезге бүлектә белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар;
д) әлеге карарның 2 пунктындагы «а»-«в» пунктчаларында аталган затлар белән бергә яшәүче яисә шушы затлар һәлак булган (үлгән) датага алар белән бергә яшәгән ата-аналар;
е) әлеге карарның 2 пунктындагы «а»-«в» пунктчаларында аталган затлар карамагындагы яисә әлеге затлар һәлак булган (үлгән) датага шушы затлар карамагындагы затлар».

1.4 3 нче пунктта «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар балаларына, Россия Федерациясе Хәрби Көчләренә, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләргә һәм затларга, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарга, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарга, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренә махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага чакырылган гражданнар, шулай ук күрсәтелгән категориядәге гражданнарның махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән затларга» сүзләрен «әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән затларга» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. 4 нче пунктта «7 яшьтән 17 яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә» сүзләреннән соң «әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән» сүзләрен өстәргә.

1.6. 5 нче пунктта «ата-ананың берсенең (законлы вәкиленең, опекунның, попечительнең)» сүзләрен «ярдәм чаралары алу хокукына ия затның» сүзләренә алмаштырырга.;

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучыларны мобилизацияләү буенча ата-аналарның (якын туганнарының) хәрби хезмәткә чакырылуы фактын раслый торган документлар белән, «махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүчеләр, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), аларга Донецк Халык Республикасы территорияләрендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәтне үтүдә түбәндәге өстәмә чаралар, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә яисә ата-аналарның берсенең (контракт хезмәте хәрбиләренең) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узуы факты, шул исәптән Россия Федерациясе Кораллы Көчләре алдына куелган бурычларны үтәүгә ирекле ярдәм күрсәтеп, Татарстан Республикасында төзелгән исемле милли батальоннарда катнашучы сыйфатында Донецк Халык Республикасы территорияләрендә, Луганск Халык Республикасы һәм Украина (Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу факты)» сүзләрен «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән исемлек нигезендә мөрәҗәгать итүченең статусын раслый торган документлар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары - Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе начальнигы (О.В. Купцовага), Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары (Г. Ю. Задворновага) йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э. Р. Хәсәнов